КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 май г.Казань № 556

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 909 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 909 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 декабрь, 1298 нче, 2022 ел, 26 гыйнвар, 47 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«VIII. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторы

Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторы булып узган ике календарь елда турыдан-туры социаль хезмәтләр күрсәтүче контрольдә тотыла торган зат белгечләренең штатлы санының социаль хезмәт күрсәтүләрнең бер алучыга исәпләгәндә 20 проценттан күбрәккә кимүе тора.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин